ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПОРУЧИКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Горбунова, зд. 2а, с.Поручиково,
Заинский район,
(индекс) 423520 тел. 3 70 49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПОРУЧИК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКОРМА КОМИТЕТЫ

Горбунов урамы, 2а номерлы
бина, Поручик авылы, Зәй районы,
(индекс) 423520 тел. 3 70 49

Телефон, факс 3-70-49. Электронный адрес: Por.Zai@tatar.ru, сайт: www.http://zainsk.tatarstan.ru/poruchikovskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31.01.2025 года** **№ 6**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте 2025 елның 23 гыйнварендагы 33 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Уставына таянып

**карар бирәм:**

1. 2025 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9165,37 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында” 2024 елның 30 гыйнварендәге 02 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручикавыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4.Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.И. Хаджаева**

Зәй муниципаль районы
Төги авыл җирлеге
башкарма комитетының
«31» гыйнвареннән 2025ел
06 номерлы карарына
1 нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән
Поручик авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе** ***(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3486,04 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1490,01 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4189,32 |
| Барысы | 9165,37 |

Зәй муниципаль районы
Төги авыл җирлеге
башкарма комитетының
«31» гыйнвареннән 2025ел
06 номерлы карарына
2нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән
Поручик авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 955,88 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2601,58 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1454,39 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4153,52 |
| Барысы | 9165,37 |